**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** — **РЕШЕНИЕ**

**17 апрель 2019 ел** — **№ 285**

## Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге” муниципаль учреждениесенең хокукый нигезен камилләштерү турында”, 2016 ел, 28 нче сентябрь, 85 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 ел, 5 нче апрель, 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге” муниципаль учреждениесенең хокукый нигезен камилләштерү турында”, 2016 ел, 28 нче сентябрь, 85 номерлы Карары (2018 ел, 14 нче декабрь, 267 номерлы Совет Карары редакциясендә) белән расланган “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.17 Мәгариф бүлеге дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне (алга таба – сатып алу) сатып алу вәкаләтләренә ия – заказ бирүче тарафыннан “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 ел, 5 нче апрель, 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тормышка ашырыла торган һәм дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар тәэмин итүгә юнәлдерелгән барлык эшләр. Сатып алу тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручы) ачыклаудан башлана һәм контракт яклары тарафыннан йөкләмәләрне үтәү белән тәмамлана. Әгәр дә 2013 ел, 5 нче апрель, 44-ФЗ номерлы Федераль закон белән сатып алуны тормышка ашыруда белдерү урнаштыру яки тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручы) ачыклауда катнашуга чакыру җибәрү каралмаса, сатып алу контракт төзү белән башлана һәм контракт якларының йөкләмәләрен үтәү белән тәмамлана;”;

2. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – мәгариф бүлеге начальнигы Әхмәтҗанов Нияз Камил улын “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе

турында Нигезләмәне яңа редакциядә дәүләт теркәве узу буенча гариза бирүче буларак чыгуны вәкаләтләргә.

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән бәйләнешләр буенча комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин